ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__520____ от «_28__»____09_____2018 г.

Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 маддәсенең 2 пункты, 2 подпункты, “Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында”, 26.12.2015 ел, ТРЗ - 108 Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 26.12.2015 ел, ТРЗ- 109 Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау хакында.

2. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
28.09.2018 ел, 520 нче санлы карары
белән расланган

**Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү Тәртибе**

1.Әлеге Тәртип сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына кергән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы һәм муниципаль берәмлекләре (шәһәр һәм авыл җирлекләре) милкендә булган җир кишәрлекләренең, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 маддәсенең 2 нче пунктының 1-5,7,9 һәм 10 пунктчасы нигезендә, бәясен кую кагыйдәләрен билгели.

2. Базар бәясен тигез, ләкин җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән артмаган хак белән түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы нигезендә территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән затка территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен;

2) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага, шәхси торак төзелеше максатларында ( уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләреннән тыш), территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына, яисә бу коммерциячел булмаган оешма әгъзаларының уртак җыелышы карары белән күздә тотылган булса, әлеге коммерциячел булмаган оешмага;

3) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен (уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләреннән тыш) бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына;

4) юридик затларның даими (вакыты чикләнмәгән) кулланылышында булган җир кишәрлекләрен ( әлеге җир кишәрлекләрендә биналар, корылмалар булмаган очракта) алда әйтелгән юридик затларга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 маддәсенең 2 нче пунктта күрсәтелгән затлардан тыш;

5) авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен каралган һәм гражданга яки юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлекләрен әлеге гражданга яки юридик затка, бу граждан яки юридик зат белән шартнамә төзү вакытыннан соң өч ел үткәч яисә, бу җир кишәрлегеннән тиешенчә файдалану шарты белән, әлеге граждан яки юридик зат бу җир кишәрлегенең сатулар үткәрмичә сату-алу шартнамәсен төзү турындагы гаризаны күрсәтелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең вакыты чыккан көнгә кадәр биргән очракта , Россия Федерациясе законнары һәм дәүләт җир күзәтчелеге белән табылган җитешсезлекләр һәм хокук бозулар турында мәгълүмат булмаган очракта, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча хокукларны һәм

бурычларны әлеге затка тапшырганда сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган шартнамә төзүнең вакыты чыкмаган очракта;
6) җир кишәрлекләрен гражданнарга шәхси торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы алып бару өчен , гражданнарга яки крестьян (ферма) хуҗалыкларының үзләренең эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен.
3.Җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән унбиш процентка тигез хак белән түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:
1) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага, шәхси торак төзелеше максатларында, территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән һәм уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерциячел булмаган оешмага;
2)юридик затка дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән һәм уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге юридик затка.
4. Җир кишәрлеге мәйданының берәмлеге өчен җир салымының 10 ставкасы күләмендә:
1) җир кишәрлегендә урнашкан биналар, төзелешләр , корылмалар милекчеләренә.